Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башкарма комитеты

Кибәч авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАРЫ

28 март, 2025 ел № 4

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кире кайтару тыела торган урыннар исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына хайваннар белән җаваплы эш итү һәм үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кибәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып Башкарма комитет Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге карар чыгарды:

1. Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кире кайтару тыела торган урыннар исемлеген кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесен хайваннарны элекке яшәү урыннарына кайтармау турында карарлар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп билгеләп куярга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Рәимов

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланды
28 март, 2025 ел, № 4

## Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кире кайтару тыела торган урыннар исемлеге

1. Балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.

2. Җәмәгать территорияләре (парк, сквер территорияләре, массакүләм ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).

3. Мәгариф һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.

4. Мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.

5. Җәмәгать туклануы оешмалары, сәүдә объектлары янындагы территорияләр, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннары.

6. Йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннар.

7. Күпфатирлы йортларга якын территорияләр, аларда урнашкан, мондый йортларга хезмәт күрсәтү һәм алардан файдалану өчен билгеләнгән объектлар һәм бу территорияләрне төзекләндерү элементлары, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары), тротуарлар һәм автомобиль юллары, моңа күпфатирлы йортларга якын территорияләргә юллар барлыкка китерүче автомобиль юллары да керә.

8. Зиратлар һәм мемориаль зоналар.